Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение
«Нижнечершилинская основная общеобразовательная школа
муниципального образования «Лениногорский муниципальный район»
Республика Татарстан

«Рассмотрено»
Руководитель ШМО начальных классов
____________Г.А.Ганиева
Протокол №1
«24» августа 2023 г.

«Согласовано»
Зам.директора по УВР
_________В.М.Вафина
«25» августа 2023 г.

«Утверждаю»
Руководитель МБОУ «Нижнечершилинская ООШ»
___________Г.К.Вафина
Приказ № 52
«25» августа 2023 г

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 070D8C0036B09BB14D93CB1CC35E9E65
Владелец: Вафина Гулия Камиловна
Действителен с 05.07.2023 до 05.10.2024

**Календарно-тематическое планирование**
учебного предмета
«Родная (татарская) литература»
для 4 класса
для образовательных организаций с обучением на родном (татарском) языке
на 2023-2024 учебный год

Составитель:
Муллагалиева Алсу Виловна
учитель татарского языка и литературы

Нижние Чершилы, 2023 год

**Дүртенче сыйныф** программасы балаларга әдәбиятның сүз сәнгате буларак башка сәнгать төрләре: сынлы сәнгать, музыка белән тыгыз мөнәсәбәттә булуын аңлатуны эзлекле рәвештә дәвам итә. Укучыга борынгы кешеләрнең, дөнья барлыкка килүен дөрес кузаллауларына ирешү максатыннан мифлар, легендалар аша гомумкешелекнең язу барлыкка килгәнгә кадәрге яшәеше аңлатыла. Төп үзенчәлек булып кешенең табигать шартларына бәйлелеге тора. 3-4 сыйныф дәреслекләре төрле халыкларның фольклор, автор әсәрләре аша әдәбият-сәнгать бердәмлеген, аларның бербөтен булуын кузалларга ярдәм итә. Әгәр укучы шуны аңлый алса, ул төрле милләт фольклор әсәрләренең төп чыганагы бер үк табигать, безне чолгап алган дөнья икәнлеген аңлый, әдәби җәүһәрләрнең кыйммәтләре уртак булуын төшенә, үз милләтенең фольклор һәм әдәби мирасының дөньякүләм әһәмиятен аңлый алачак. Бу уку елы халык авыз иҗатыннан авторлар әсәрләренә күчү чоры булып тора. Төрле жанрлар арасындагы аермалар тирәнрәк өйрәнелә. Балаларның уку күнекмәләре киңәя. Анализ өчен төп әдәбият булып элеккечә үк хәзерге балалар әдәбияты һәм классик әсәрләр кала. Бүгенге балалар әдәбияты белән таныштыру да бик мөһим, чөнки ул балаларның һәм өлкәннәрнең бүгенге яшәү рәвешенә якын. Сынлы сәнгать әсәрләре белән танышу дәвам ителә. Алар темалары һәм эчтәлекләре белән шул әдәби әсәргә бик якын булалар. Программа поэтик форманың кайбер әһәмиятле үзенчәлекләре белән таныштыруны күз алдында тота. Укучылар, парлы һәм арадаш рифмаларның дөрес яңгырашын, эчтәлеккә йогынтысын бәяли алачаклар. Төрле рифмаларның чиратлашуы аша ритм төшенчәсе дә бирелә.

**Дүртенче сыйныф** дәреслекләренең төп үзенчәлеге төп һәм урта мәктәп программасын җиңел үзләштерү өчен җирлек әзерләү. Фольклор һәм автор әсәрләренең төрле жанрларын анализлый һәм әсәргә бәя белергә өйрәтү. Фольклор текстлар (тылсымлы әкиятләр һәм мифлар, легендалар) аша тарихи материаллар белән — төрле атамалар, кешеләрнең тормыш-көнкүреше белән таныштыру. Әдәби әсәрләрдәге хәрәкәт үсешен тоемларга җирлек хәзерләү, үзләренә кадәр яшәгән яшьтәшләренең тормышы белән танышу. (19 нчы гасыр ахыры), шул чорның үзенчәлекле якларын күрсәтү. Дәреслекнең икенче төп максаты — кече яшьтәге мәктәп баласына авторларның күзәтүләре, алар чагылдырган фикерләрне аңлый һәм үз фикерләрен әйтә белергә, өйрәтү. “Мин үзем” — укучы менә шушы максатка омтылып яшәсен.

Поэтик текстлар укучы аңына барып җитәрлек, сәнгатьле итеп укый алырлык, анализлый һәм ритм, рифмаларны дөрес аера алырлык булырга тиеш.

Укучы зур күләмле әсәрләрне дә ашыкмыйча, геройлар белән бергә яшәп, алдагы эпизодлар белән бәйли белеп укырга омтылсын, автор фикерләренә үз бәясен бирә белсен.

Дәреслек-хрестоматия әдәби әсәрләрнең төрлелеген арттыру өчен (дәреслек еш кына хрестоматиягә мөрәҗәгать и) хезмәт итә. укучыларны мөстәкыйль белем алырга хәзерли.

“Музей йорты” дәреслек куйган максатларны тормышка ашырырга ярдәм итә.

Дүртенче сыйныфны тәмамлаганда укучылар әдәби процессның хәрәкәтен кузалларга, төрле халыкларның әдәбиятлары үсешенең тамырлары бер булуын төшенергә, әдәби образның прозада һәм поэзиядә үзенчәлекле кичерешләрен аңларга тиешләр.

## Әдәби уку дәресләре программасы, 4 нче сыйныф (68 сәг)

### Халык авыз иҗаты

**Мифлар турында гомуми кузаллау булдыру.** Борынгы халыкларның тормышы, кеше һәм табигать арасындагы мөнәсәбәт. Тормыш агачы, тотем хайваннар һәм тотем үсемлекләр, кешеләрнең аларга карашы, борынгы традицияләрнең сакланышы.

**Тылсымлы әкиятләр.**

Дөнья турында борынгы кузаллаулар чагылышы. Тылсымлы әкият герое. Тылсым дөньясы, тылсымлы предметлар, сихри саннар, сүзләр, тылсымлы булышчылар. Тылсымлы әкият законнары: әкият герое өеннән чыгып китә, максатка ирешү юлы (тылсым дөньясы, карурманнар аша үтүче юл, сынаулар, тылсымлы булышчы ярдәме, җиңү шатлыгы). Халыклар әкиятләренең мифлар, легендаларда чагылышы.

**Риваять һәм легендалар.**



Документ создан в электронной форме. № 52 от 25.08.2023. Исполнитель: Вафина Г.К.
Страница 2 из 6. Страница создана: 15.04.2024 13:25

Риваять һәм легендаларда сөйләнгән геройлятьар, аларның кичерешләре. Тарихи бәйләнеш. Төрле атамалар, аларның килеп чыгышы. Риваять һәм легендаларда бирелгзн вакыйгаларның әкиятләрдә чагылышы.

**Автор әкиятләре**

Автор әкиятләренең халык әкиятләре белән охшашлыгы. (жанр һәм сюжет). Халык әкиятләрендәге тылсым белән җиңүләр, автор әкиятләрендә акыл белән эш итеп уңышка ирешү, ярату һәм яратыла белүнең көче.

**Фольклор жанрының тормышта, хәзерге вакытта яшәеше.**

Халык традицияләре һәм бәйрәмнәре. Гимннар (Татарстан гимны). Халык һәм автор әкиятләре.

**Хикәя**

Хикәя жанры турында кузаллау формалаштыруны дәвам итү**.** Хикәя геройлары, аларның портретлары һәм характер үзенчәлекләре, башкарган гамәлләре аша чагылышы. Авторның үз героена мөнәсәбәте. Геройларга чагыштырма характеристика. Герой характерының катлаулылыгы, вакыт белән бәйләнеше. Герой яшәгән тирәлек, пейзаж. Хикәядәге чынбарлык чагылышы. Әдәби тел берәмлекләре.

**Әкият һәм хикәя жанрының үзгәлеге турында кузаллау формалаштыру.** Әкият һәм хикәя жанрларының композиция үзенчәлеген (күзәтүләр аша) аңлату. Укучы-тыңлаучыга табигый көчләрнең серен, әкият геройларының серле тормыш агышын күрсәтү, хикәя геройларының характерын тормыштан алынган вакыйгаларны чагылдырып сөйләү.

**Шигърият.** Кеше һәм табигать бергәлеге. Дөньяны шагыйрь күзлегеннән чыгып кузаллау. Әйләнә-тирә дөньяның матурлыгы — шагыйрь өчен илһам чишмәсе булуга инандыру. Шигырьдә чагыштыру, сынландыру, эпитет. Автор әсәрләрендә һәм халык авыз иҗатында охшашлык. Чагыштыру, контраст, җанландыру кебек гади әдәби алымнарны таба белү. Җанлы сөйләмнең мөһим чараларын үзләштерү күнегүләре: темп, тавыш көче, тон, сөйләм мелодикасы (тавышны күтәрү, түбәнәйтү).

**Әсәр авторлары турында**

Шагыйрь, язучы, рәссамнарның биографиясе.

а) әсәрдә авторлар кичереше;

ә) автор күзәтүләренең чагылышы;

б) хәзерге заман авторлары белән очрашу, балаларның авторга сораулары, җаваплар.

**Библиографик культура формалаштыру.**

“Эчтәлек ” белән танышу , аңа карап, кирәкле әсәрне китаптан таба белү, кече яшьтәге мәктәп баласының дәреслектән тыш эшчәнлеген оештыру: өй, мәктәп китапханәләреннән файдалану. Фән буенча сүзлек, белешмә әдәбият, вакытлы матбугат белән эшләү. Балалар китабы белән эшләү. Китапның төп төп элементларын аеру: китап тышлыгы, китап төпсәсе, битләре. Китапны саклап тоту күнекмәләре булдыру. Төрле җыентыклар төзергә өйрәнү. Әсәр авторлары турында мәгълүмат туплау.

**Уку, сөйләү, тыңлау күнекмәләре формалаштыру**

Сәнгатьле уку күнекмәләре формалаштыру (интонация, тон, темп саклап кычкырып уку) Автор бирергә теләгән картинаны кузаллау. Эчтән укый белергә күнектерү. Чылбыр рәвешендә укыганда үз урыныңны белеп , чират буенча уку. Укылган әсәргә анализ ясау. Уку техникасын үстерү.

**4 нче сыйныфны тәмамлаганда укучыларның белеменә, эш осталыгына, һәм күнекмәләренә таләпләр.**

— әсәрне сүзләрне дөрес әйтеп кычкырып һәм эчтән укый белү;

— әсәрнең темасын, төп мәгънәсен ачыклау, мәгънәви кисәкләргә бүлү, алар арасындагы бәйләнешләрне, төп фикерне билгеләү һәм аны үз сүзләрең белән әйтеп бирү;

— фольклор жанрларын аеру: хайваннар турындагы, тылсымлы әкиятләрне өйрәнү, мәсәл, хикәя, турында кузаллау, халык иҗаты әсәрләре һәм автор әсәрләрен төркемли белү;

— әсәр геройларын характерлый белү, авторның үз героена мөнәсәбәтен күрсәтү, геройларга чагыштырма характеристика бирү;



Документ создан в электронной форме. № 52 от 25.08.2023. Исполнитель: Вафина Г.К.
Страница 3 из 6. Страница создана: 15.04.2024 13:25
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

— төрле авторларның 6-8 шигырен яттан сөйләү;
— кыска күләмле әсәрләрнең эчтәлеген сөйләү;
— укылган әсәрдән чагыштыру, җанландыру, контрастны таба белү;
— сүзлекләрдән файдалану, тематик сүзлекләр төзү;
— аерым әсәрләргә аннотация төзү;
— элементы буенча китапта ориентлашырга өйрәтү (авторы, исеме, “Эчтәлек” бите, иллюстрацияләр)

**Укучы белергә тиеш:**
— 4-5 татар, рус, чит ил классикларының исемен, аларның әсәрләрен;
— 1-2 балалар журналы һәм газетасының исемен, алрдагы рубрикаларны;
— 4-5 хәзерге заман язучы яки шагыйренең исемен, алар язган әсәрләрне һәм эчтәлеген;
— үзенә иң ошаган авторның берничә әсәрен.
**Алынган белемнәрне көндәлек тормышта куллану.**
— китапның төрле элементларына карап эчтәлеген билгеләү;
— китапханәдә мөстәкыйль рәвештә уку өчен китап сайлау;
— укылган әсәр геройларын тасвирлап сөйләү;
— төрле чыганаклардан кирәкле мәгълүматны табу;

**Әгәр укыту планында “Әдәби уку” фәненә 1 сәгать вакыт бирелсә, дәрес материалы түбәндәгечә планлаштырыла ала.**

| № | Дәрес темасы | Дата | План | Факт | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| **1.Тылсымлы экият кануннарын өйрәнәбез: үткәннәрне яңадан кичереп, бүгенге тормыш белән бәйлибез (7 сәгать)** | | | | | |
| 1 | Җир йөзендә яшәгән беренче кешеләр | 8.09.23 | | | |
| 2 | Җир ничек барлыкка килгән? | 13.09 | | | |
| 3 | Тотем агачлар, тотем хайваннар | 20.09 | | | |
| 4 | Туган як сылуы — ак каен | 27.09 | | | |
| 5 | Абага чәчәге | 4.10 | | | |
| 6 | Татар мифологиясендә Ак бүре. Татарстан гербы | 11.10 | | | |
| 7 | Әкиятләрдә Ак елан. Еланнар патшасы Шаһмара | 18.10 | | | |
| **2. Фольклорга нигезләнгән хикәяләү. Дастан, риваять һәм легендалар аша тарих белән танышабыз, ә автор экиятләре хисләр дөньясына чакыра (4 сәгать)** | | | | | |
| 8 | Борынгы ша-гыйрь — Кол Гали | 25.10 | | | |
| 9 | Нәсел агачы | 8.11 | | | |
| 10 | Су асты патшалыгында | 15.11 | | | |
| 11 | Су кызы Айсылу –бәхетле бала | 22.11 | | | |
| **3. Шагыйрьләр һәм рәссамнар иҗаты аша табигать һәм кешеләрнең матурлыгын аңларга өйрәнәбез (4сәгать)** | | | | | |
| 12 | Җирдә миңа ни кирәк? Шәехзадә Бабич шигырьләре | 29.11 | | | |



Документ создан в электронной форме. № 52 от 25.08.2023. Исполнитель: Вафина Г.К.
Страница 4 из 6. Страница создана: 15.04.2024 13:25
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 13 | Көзге табигать мизгелләре | 6.12 | | | |
| 14 | Әнкәм портреты | 13.12 | | | |
| 15 | Кеше ышан-маслык сүзне чын булса да сөйләмә | 20.12 | | | |
| **4. Безгә кадәр яшәгән яшьтәшләребез тормышы белән танышабыз (3 сәгать)** | | | | | |
| 16 | Газаплы язмыш | 27.12 | | | |
| 17 | Күз яшьле балачак | **10.01.24** | | | |
| 18 | Балачак хатирәләре | 17.01 | | | |
| **2 нче кисәк**<br>**5. Матурлыкның безгә ничек тәэсир итүен аңларга тырышабыз (6 сәгать)** | | | | | |
| 19 | Көннәрем гөрләп торсын. Каен- урман чибәре. | 24.01 | | | |
| 20 | Бөтен дөнья ак кына | 31.01 | | | |
| 21 | Язгы моң | **7.02** | | | |
| 22 | Матурлык дөньясы | 14.02 | | | |
| 23 | Табигать - серле дөнья | 21.02 | | | |
| 24 | Аккошлар — сак кошлар. Сандугач— табигать җырчысы | 28.02 | | | |
| **6. Җирдә кеше булу өчен, кеше күпме юллар үтә? (4 сзгать)** | | | | | |
| 25 | Кирлемән маҗаралары | 6.03 | | | |
| 26 | Урман докторы | 13.03 | | | |
| 27 | Гөмбәләр серен белү кирәк | 20.03 | | | |
| 28 | Бану әби сабагы | 3.04 | | | |
| **7.Сәнгать дөньясының үзенә генә хас үзенчәлекләрен ачыклыйбыз** | | | | | |
| 29 | Язучы катнашында үткән “Серле ачкыч” мәктәп клубы утырышы | 10.04 | | | |
| 30 | Чыпчыкның да үз җыры бар | 17.04 | | | |
| | | | | | |
| **8. Үткәне булмаган халыкның киләчәге юк. Туган ил турында уйланабыз** | | | | | |
| 31 | Һәркемгә үз Ватаны кадерле<br>Татарстан флагы | ***24.04*** | | | |
| 32 | Зур тарихлы батыр халкым | 8.05 | | | |
| 33 | Авыр елларда | 15.05 | | | |
| 34 | Кыю очучылар | ***22.05*** | | | |



Документ создан в электронной форме. № 52 от 25.08.2023. Исполнитель: Вафина Г.К.
Страница 5 из 6. Страница создана: 15.04.2024 13:25
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Лист согласования к документу № 52 от 25.08.2023
Инициатор согласования: Вафина Г.К. Директор
Согласование инициировано: 15.04.2024 13:25

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Вафина Г.К. | | Подписано<br>15.04.2024 - 13:25 | - |